МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

02.12.2024 ел_ №_96__

Казан ш.

Татарстан Республикасы Транспорт һәм
юл хуҗалыгы министрлыгының 2012
елның 27 июлендәге 127 номерлы
боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан әзерләнә торган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында» 2012 елның 27 июлендәге 127 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 24.06.2013 ел, №112, 23.06.2014 ел, №196, 19.10.2018 ел, №532, 07.03.2023 ел, №51, 17.07.2023 ел, №177 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны көчен югалткан дип танырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан әзерләнә торган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибендә:

19 пунктта «аны Министрлык тарафыннан әзерләнә торган норматив хокукый актлар проектларын коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен урнаштыруга җаваплы затка (алга таба – норматив хокукый актлар проектларын урнаштырган өчен җаваплы зат) җибәрә» сүзләрен «аны урнаштыра» сүзләренә алмаштырырга;

20 пунктны көчен югалткан дип танырга;

21 пунктта «аны норматив хокукый актлар проектларын урнаштыру өчен җаваплы затка җибәрә» сүзләрен «Министрлыкның рәсми сайтында һәм бердәм региональ интернет-порталында урнаштыра» сүзләренә алмаштырырга;

22 пунктны көчен югалткан дип танырга;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясындагы 3 өлеше нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга.

Министр Ф.М. Хәнифов